ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СУНЬСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Яруллина, д.7а, с.Малая Сунь,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422173

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ СОН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Яруллин ур., 7а йорт, Кече Сон авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422173

тел.(факс): (85563) 3-07-03; e-mail: : Sun.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Постановление — Карар

“ 05 ” июнь 2018 ел — № 6

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Сон авыл җирлеге Башкарма комитетының 2014 елның 19 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Сон авыл җирлегенең халык дружинасы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 82 нче карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Гражданнарның җәмәгать тәртибен саклауда катнашуы турында» 02.04.2014 елның 2 апрелендәге № 44-ФЗ Федераль закон, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Сон авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, к а р а р б и р ә м:

1. «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Сон авыл җирлеге Башкарма комитетының 2014 елның 19 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Сон авыл җирлегенең халык дружинасы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 82 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. II бүлекнең 5 пунктындагы 8 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«халык дружинасы оешу көненә кадәр ел дәвамында берничә тапкыр Административ хокук бозулар өчен суд тәртибендә административ җаваплылыкка тартылган».

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) юлы белән бастырып чыгарырга(халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Мамадыш муниципаль районы
Сон авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе /М.Ф.Сәләхов/